ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
пр. Мира 12, г. Елабуга, 423603

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Тынычлык пр.12, Алабуга шәһәре, 423603

тел.(85557) 30832, факс.(85557)34211, ik.elb@tatar.ru, сайт: городелабуга.рф

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 15 17.01.2020

«2017 - 2019 елларга Алабуга муниципаль районының әйләнә – тирә мохитен саклау» программасын раслау турында» Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 24 декабрендәге 41 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2014 елның 9 июлендәге 765 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2017-2019 елларга Алабуга муниципаль районынның әйләнә-тирә мохитен саклау» программасын раслау турында» Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 24 декабрендәге 41 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2017-2022 елларга Алабуга муниципаль районының әйләнә-тирә мохитен саклау» программасын раслау турында»

2. «Алабуга муниципаль районының 2017-2022 елларга әйләнә-тирә мохитен саклау» муниципаль программасын яңа кушымта итеп бирелә торган редакциядә расларга.

3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына «Алабуга муниципаль районының 2017-2022 елларга әйләнә-тирә мохитен саклау» муниципаль программасын гамәлгә ашыру чыгымнарын каварга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л.Ф. Нургаяновка йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Нуриев

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“17” 01 2020 ел
15 карарына 1 нче кушымта

# «Алабуга муниципаль районының 2017-2022 елларга әйләнә-тирә мохитен саклау» муниципаль программасы

**«Алабуга муниципаль районының 2017-2022 елларга әйләнә-тирә мохитен саклау» муниципаль программасы паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «Алабуга муниципаль районының 2017-2022 елларга әйләнә-тирә мохитен саклау» муниципаль программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 10.01.2002 ел, 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль закон, ТР Экология Кодексы. |
| Программаны төп эшләүчеләр | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты, ТР экология һәм табигый байлыклар Министрлыгының Кама буе территориаль идарәсе (килешү буенча) |
| Программаны башкаручылар | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты, ТР Экология һәм табигый байлыклар Министрлыгының Кама буе территориаль идарәсе, Алабуга муниципаль районы оешмалары (килешү буенча) |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның төп максатлары булып:<br>- районда экологик хәлне саклауга һәм тотрыклыландыруга юнәлтелгән конкрет чараларны гамәлгә ашыру;<br>- әйләнә-тирә табигать компонентлары буларак табигый ресурсларны саклау һәм яңадан җитештерү буенча чараларны гамәлгә ашыру;<br>- хуҗалык эшчәнлегенең экологик куркынычсызлыгын арттыру.<br>Программаның бурычлары:<br>- калдыкларны эшкәртү һәм утильләштерү системасын кертү;<br>- район территориясендә табигый ландшафтларны яшелләндерү һәм саклау аша экологик-табигый каркас булдыру. |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты | 2017-2022 еллар |
| Программаны финанслауда ихтыяҗ күләме | Программаны финанслау күләме-52 646,8 мең сум.,<br>шул исәптән:<br>2017 ел – җирле бюджет хисабына-5519,3 мең сум.<br>2018 ел – җирле бюджет хисабына-7077,3 мең сум.<br>2019 ел – җирле бюджет хисабына-19952,9 мең сум.<br>2020 ел – җирле бюджет хисабына-6699,1 мең сум.<br>2021 ел – җирле бюджет хисабына-6699,1 мең сум.<br>2012 елда - җирле бюджет хисабына – 6699,1 мең сум. |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм күрсәткеч нәтиҗәлелеге | Табигать ресурсларын (урманнарны, атмосфера һавасын, су, җир (туфрак), үсемлекләр ресурсларын, хайваннар дөньясы объектларын) саклау һәм рациональ файдалану өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, табигатьтән файдалану нәтиҗәсендә экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү, шул исәптән җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш иткәндә дә, биологик төрлелекне саклау. |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру | Программаны гамәлгә ашыруны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты контрольдә тота. |

## Кереш

Әлеге Программа «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 10.01.2002 ел, 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль закон, ТР Экология Кодексы нигезендә эшләнгән.

Программа Алабуга муниципаль районында экологик хәлне яхшыртуга юнәлтелгән чараларны үтәүгә бәйле муниципаль программаларны әзерләү һәм гамәлгә ашыру тәҗрибәсен исәпкә алып эшләнгән.

Әлеге Программа Алабуга муниципаль районы территориясенең төп экологик проблемаларын хәл итүгә ярдәм итү дип танылды.

Программа әйләнә-тирәлекнең сыйфатын яхшырту нигезендә гражданнарның уңайлы яшәү шартларын булдыруга, хуҗалыкның аерым тармаклары һәм территорияләр белән идарә итү системасын камилләштерүгә, Алабуга муниципаль районында хуҗалык эшчәнлегенең экологик куркынычсызлыгын арттыруга юнәлдерелгән.

Программаның төп юнәлешләре булып: һава бассейнын, су ресурсларын саклау, җитештерү һәм куллану калдыкларын утильләштерү, табигый-экологик кадастрны үстерү һәм биологик төрлелекне саклау чаралары тора.

## 1. Программаның максат һәм бурычлары

Программаның төп максатлары булып:

1. Алабуга муниципаль районында экологик хәлне саклауга һәм тотрыклыландыруга юнәлтелгән конкрет чараларны гамәлгә ашыру;
2. әйләнә-тирә табигый мохит компонентлары буларак табигый ресурсларны саклау һәм яңадан җитештерү буенча чараларны гамәлгә ашыру;
3. хуҗалык эшчәнлегенең экологик куркынычсызлыгын арттыру тора.

Программаның бурычлары:

1. калдыкларны эшкәртү һәм утильләштерү системасын кертү;
2. Алабуга муниципаль районы территориясендә ландшафтларны яшелләндерү һәм саклау аша экологик-табигый каркас булдыру.

Әйләнә-тирә мохиткә һәм халыкның сәламәтлегенә тискәре йогынтыны бетерү, әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләрен хәл итү-бу муниципаль программа тарафыннан оештырыла торган чараларның бердәм системасы.

Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге проблемаларны комплекслы хәл итү зарурилыгы түбәндәге объектив сәбәпләргә бәйле:

- экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү проблемаларының масштабы, катлаулылыгы һәм күптөрлелеге, бу конкрет бурычлар, ресурслар, тормышка ашыру вакыты һәм башкаручыларга бәйле программа чаралары комплексын эшләүне һәм гамәлгә ашыруны күздә тота;
- бердәм муниципаль программа кысаларында күләме буенча зур һәм озак сроклы проектларны гамәлгә ашыруны таләп итә;
- федераль башкарма хакимият органнарының, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнарының (федераль һәм өлкә бюджетларыннан финанслау өлешендә), җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның тырышлыкларын координацияләү ихтыяҗы.

## 2. Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

Программаны гамәлгә ашыру вакыты - 2017 – 2022 еллар

Калдыкларны утильләштерү һәм эшкәртү, атмосфера һавасын саклау, су һәм җир ресурсларын саклау һәм рациональ файдалану, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларын саклау буенча чаралар гамәлгә ашырылачак.

## 3. Программаны финанслау күләме, чыганаклары һәм структурасы

Программаны финанслау күләме 57 026,5 мең сум тәшкил итә.
Программаны үтәү Алабуга муниципаль районы, ТР бюджеты һәм бюджеттан тыш акчалар хисабына башкарыла.

мең сум.

| Финанслау чыганаклары | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| Алабуга муниципаль районы бюджеты | 52646,8 | 5519,3 | 7077,3 | 19952,9 | 6699,1 | 6699,1 | 6699,1 |
| Барлыгы: | 52646,8 | 5519,3 | 7077,3 | 19952,9 | 6699,1 | 6699,1 | 6699,1 |

## 4. Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру

Программаны гамәлгә ашыру барышын Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тикшереп тора.

Программаны гамәлгә ашыру турында түбәндәге хисап мәгълүматлары тапшырыла:

- хисап чорыннан соң килә торган айның 25 числосына кадәр Алабуга муниципаль районының перспектив социаль - икътисадый үсеш палатасына муниципаль программаларны әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасында күрсәтелгән форма буенча тутырып, финанс чараларын куллануның нәтиҗәлелеге турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат;

- ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 1 мартына кадәр, Алабуга муниципаль районының перспектив социаль-икътисади үсеш палатасына, Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына программаларны гамәлгә ашыру һәм финанс чараларын куллануның нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат.

## 5. Муниципаль программаны гамәлгә ашыруда көтелгән соңгы нәтиҗәләр

Муниципаль программа чараларын үтәү нәтиҗәсендә түбәндәгеләр тәэмин ителәчәк:
- әйләнә-тирә мохит торышын яхшырту һәм аңа хуҗалык эшчәнлеге зыянлы йогынтыны киметү;
- халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген яхшырту;
- экологик белем һәм белем дәрәҗәсен күтәрү;

Муниципаль программаны гамәлгә ашырганда хәвеф-хәтәрләр барлыкка килүне булдырмауга һәм анда каралган ахыргы нәтиҗәләргә ирешүнең гарантияле дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар гамәлгә ашырыла.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыруга бәйле хәвеф-хәтәрләр инфляция процесслары, эшләр яки хезмәтләр башкару өчен оешмалар белән төзелгән муниципаль контрактларның таләпләрен үтәмәү, җир тетрәүләре, янгыннар, су басулар белән бәйле гадәттән тыш хәлләр аркасында килеп чыгарга мөмкин. Хәвеф-хәтәрләрне киметү буенча чаралар булып, муниципаль программаның һәр конкрет чарасын гамәлгә ашыруны контрольдә тоту тора.

Программа чаралары исемлеге әлеге муниципаль программаның кушымтасында күрсәтелгән.

Кушымта

## «Алабуга муниципаль районының 2017-2022 елларга әйләнә-тирә мохитен саклау» муниципаль программасы чаралары

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Бәяләү индикаторлары ахыргы нәтиҗәләр, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | | | Финанслау (АМР бюджеты һәм бюджеттан тыш акчалар хисабына), мең сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
| Пионер паркын яшелләндерү (2 чират) | Алабуга шәһәре Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2017 ел | Шәһәр һәм район территорияләренең санитар-экологик торышын яхшырту | 100 | - | - | - | - | - | 2700,00 МБ | - | - | - | - | - |
| 2. Шишкин буалары территориясендә урман массивын торгызу | Алабуга шәһәре Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2017 ел | Шәһәр һәм район территорияләренең санитар-экологик торышын яхшырту | 100 | - | - | - | - | - | 1 609,10 МБ | - | - | - | - | - |
| 3 Түбәндәге адрес буенча урнашкан сибирязва үләт базының санитар-яклау зонасын киметү өчен проект эшләү: ТР, Алабуга шәһәре, төньяк-0,22 км) | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2017 ел | 1.Инженерлык тикшеренүләрен уздыруга йөкләмә һәм чыгымнарны исәпләү (смета исәп-хисап);<br>2.Проект документларын эшләү: шул исәптән проект һәм эш документлары;<br>3.Дәүләт һәм экологик экспертиза үткәрү | 100 | - | - | - | - | - | 2 474,62 МБ | - | - | - | - | - |
| 4. Түбәндәге адрес буенча урнашкан себерязвасы үләт базының санитар-яклау зонасын киметү өчен проект эшләү: ТР, Алабуга районы, Хлыстово авылы, 1 км көнбатыштарак) | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2017 ел | 1.Инженерлык тикшеренүләрен уздыруга йөкләмә һәм чыгымнарны исәпләү (смета исәп-хисап);<br>2.Проект документларын эшләү: шул исәптән проект һәм эш документлары;<br>3.Дәүләт һәм экологик экспертиза үткәрү | 100 | - | - | - | - | - | 2 474,62 МБ | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. Түбәндәге адрес буенча урнашкан себерязвасы үләт базының санитар-яклау зонасын киметү өчен проект эшләү: ТР, Алабуга районы, Колосовка авылы | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2018 ел | 1.Инженерлык тикшеренүләрен уздыруга йөкләмә һәм чыгымнарны исәпләү (смета исәп-хисап);<br>2.Проект документларын эшләү: шул исәптән проект һәм эш документлары;<br>3.Дәүләт һәм экологик экспертиза үткәрү | - | 100 | - | - | - | - | - | 2 474,62 МБ | - | - | - | - |
| 6. Түбәндәге адрес буенча урнашкан себерязвасы үләт базының санитар-яклау зонасын киметү өчен проект эшләү: ТР, Алабуга районы, Красная Горка авылы | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2018 нче ел | 1.Инженерлык тикшеренүләрен уздыруга йөкләмә һәм чыгымнарны исәпләү (смета исәп-хисап);<br>2.Проект документларын эшләү: шул исәптән проект һәм эш документлары;<br>3.Дәүләт һәм экологик экспертиза үткәрү | - | 100 | - | - | - | - | - | 2 474,62 МБ | - | - | - | - |
| 7. Түбәндәге адрес буенча урнашкан себерязвасы үләт базының санитар-яклау зонасын киметү өчен проект эшләү: ТР, Алабуга районы, Анзирка авылы | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2018 нче ел | 1.Инженерлык тикшеренүләрен уздыруга йөкләмә һәм чыгымнарны исәпләү (смета исәп-хисап);<br>2.Проект документларын эшләү: шул исәптән проект һәм эш документлары;<br>3.Дәүләт һәм экологик экспертиза үткәрү | - | 100 | - | - | - | - | - | 2 474,62 МБ | - | - | - | - |
| 8. Шишкин буалары территориясендә сазлыкны планлаштыру һәм киптерү буенча эшләр башкару | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2019 ел | Үзәнне тәртипкә салу чараларын үткәрү:<br>- елга төбен тирәнәйтү;<br>- елга үзәнен киңәйтү һәм ныгыту;<br>- агач куакларыннан һәм чүп-чардан чистарту | - | - | 100 | - | - | - | - | - | 2 858,204 МБ | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9. "Татарстан Республикасы Алабуга ш. Куйбышев сусаклагычы Тойма елгасы тамагының Кама елгасы ярларын ныгыту" объекты буенча проект документациясенә төзәтмәләр кертү (2 чират) | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2019 ел | 1.Проект документларын эшләү: шул исәптән проект һәм эш документлары;<br>2.Дәүләт һәм экологик экспертиза үткәрү | - | - | 100 | - | - | - | - | - | 1 925,896 МБ | - | - | - |
| 10. "Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Елово авылы янында урнашкан ГТК ( ГТС) капиталь ремонтлау" объекты буенча проект эшләрен башкару (эш документларын, проект документларын ,инженер-геодезия эзләнүләрен әзерләү, дәүләт экспертизасы) | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2020 ел | | - | - | - | 100 | - | - | - | - | - | 657,429 МБ | - | - |
| 11. Түбәндәге адрес буенча урнашкан себерязвасы үләт базының санитар-яклау зонасын киметү өчен проект эшләү: ТР, Алабуга районы, Олы Качык авыл җирлеге, Малореченский б. | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2020 ел | 1.Инженерлык тикшеренүләрен уздыруга йөкләмә һәм чыгымнарны исәпләү (смета исәп-хисап);<br>2.Проект документларын эшләү: шул исәптән проект һәм эш документлары;<br>3.Дәүләт һәм экологик экспертиза үткәрү | - | - | - | 100 | - | - | - | - | - | 2 450,000 МБ | - | - |
| 12.Алабуга ш. Шумиха елгасы үзәнен тәртипкә салу чаралары өчен проект эшләү | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2020 ел | 1.Проект документларын эшләү: шул исәптән проект һәм эш документлары;<br>2.Дәүләт һәм экологик экспертиза үткәрү | - | - | - | 100 | - | - | - | - | - | 2 124,55 МБ | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 13.Алабуга районы, Алабуга шәһәрләре үзәнне тәртипкә салу чаралары өчен проект эшләү | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2020 ел | Үзәнне тәртипкә салу чараларын үткәрү:<br>- елга төбен тирәнәйтү;<br>- елга үзәнен киңәйтү һәм ныгыту;<br>- агач куакларыннан һәм чүп-чардан чистарту | - | - | - | 100 | - | - | - | - | - | 2 124,55 МБ | - | - |
| 14.АМР Бехтерев, Олы Качык, ЕМР, Олы Елово авыл жирлекләре, ЕМР, Костенеево авыл жирлекләре, ЕМР, Лекарево, ЕМР, Лекарево, ЕМР, Морт авыл җирлекләре, Иске Күклек, Татар Дөм-Дөме авыл жирлеге) Россия гидротехник корылмалар регистрына кертү | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты | 2020 ел | Эш документларын, проект документларын әзерләү ,инженер-геодезия эзләнүләре, дәүләт экспертизасы | - | - | - | 100 | - | - | - | - | - | 600,000 МБ | - | - |